СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

24.10.2018 | д. им. М. Вахитова | № 52-241

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2.03.2007 ел, № 25-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы 27.09.2017 ел № 33-150 нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7.3.3 пунктына киләсе эчтәлектәге 2.1. пунктчасын өстәргә:

«2.1). коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады (анда аны башкаруның фактлагы шартлары бәян ителә) һәм муниципаль хезмәткәрнең аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән (Ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне кулланудан тыш)»;

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга

Совет Рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы урынбасары М.К. Идиятуллин